| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Зеленодольск | **КАРАР** |
| **28.08.2018** | шәһәре | **№ 1715** |

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру тәртибе турында

1994 елның 21 декабрендәге«Янгын куркынычсызлыгы турында» 69-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 123-ФЗ номерлы Федераль закон һәм янгын куркынычсызлыгын, халыкның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибен расларга.
2. Янгынга каршы махсус режим кертү турындагы мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чаралары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http:zelenodolsk.tatarstan.ru) кичекмәстән халыкка һәм түләүсез нигездә җиткерелә дип билгеләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А.Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 28 августындагы
1715 номерлы карарына
кушымта

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә
янгынга каршы махсус режим урнаштыру
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртиптә махсус янгынга каршы режим дигәндә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яисә территориясенең бер өлешендә янгын куркынычы арткан очракта, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты билгеле торган өстәмә янгын куркынычсызлыгы таләпләре системасы аңлашыла.

2. Янгынга каршы махсус режим янгын куркынычы арткан очракта, шул исәптән уңайсыз климат шартлары, урман янгыннары, авыл торак пунктларында, балалар сәламәтләндерү лагерьларында, шулай ук потенциаль куркыныч объектларда, тимер юл һәм башка транспорт магистральләрендә зур аварияләргә китергән, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген куркыныч астына куйган һәм кичекмәстән янгыннарны кисәтү яки бетерү буенча гамәлләр таләп иткәндә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең норматив хокукый акты белән билгеләнә.

3. Янгынга каршы махсус режим урнаштырылган чорда янгын куркынычы булган хәл барлыкка килгән урында түбәндәге өстәмә чаралар билгеләнә:

- транспорт чараларының махсус керү режимы һәм иректе хәрәкәтен чикләү, шулай ук янгын урыннарында һәм аларга якын территорияләрдә гражданнарның хәрәкәтен чикләү;
- янгын урыннарында һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итүче объектлар тәртибен саклауны көчәйтү;
- халыкны, балалар сәламәтләндерү лагерьлары җитәкчеләрен янгын турында хәбәр итү тәртибен һәм янгын куркынычы янаганда торак пунктларга, балаларның ял итү һәм сәламәтләндерү объектларына, шул исәптән халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәрен (терәк-хәрәкәт аппараты бозылган инвалидларны, күрү һәм ишетү сәләте начар булган кешеләрне, өлкән яшьтәге кешеләрне) куркынычсыз урыннарга эвакуацияләү тәртибен, әлеге чараларны үткәрүче җаваплы вазыйфаи затларны билгеләп, урнаштыру;
- балалар сәламәтләндерү лагерьларында янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм янгыннар вакытында гамәлләр турында халык, персонал һәм балалар белән аңлату эшләре алып бару;
- беренчел янгын сүндерү чаралары белән (сулы чиләк, көрәк, янгын сүндерүче) җирле халык, иректе янгын сүндерү формированиеләре әгъзалары, балалар сәламәтләндерү лагерьлары персоналы көче тарафыннан торак пунктлар территориясен, балаларның ял итү урыннарын патрульләү оештыру;
- коры, эссе, җилле һава шартларында, авыл торак пунктларында, оешмаларда, бакчачылык ширкәтләрендә һәм дача-төзелеш кооперативларында, балалар сәламәтләндерү лагерьларында давыл турында кисәтү алганда, билгеле бер

участокларда янгын куркынычы булган эшләрне , каты ягулыкта эшли торган мичләрне, ашханә учакларын һәм котельный җайланмаларын яндыруны вакытлыча туктатып торырга;
– учаклар кабызуны, чүп-чар яндыруны, коры үсемлекләрне (шул исәптән камыл, корыган һәм бәйләнгән калдыкларны, коры үләннәрне, яфракларны һәм камышларны), күрсәтелгән эшләр өчен махсус билгеләнгән урыннардан тыш, янгын куркынычы булган барлык төр эшләр башкаруны тыю;
– хезмәт эшчәнлеге урманнарда һәм табигый паркларда булу белән бәйле булган гражданнардан тыш, гражданнарның урманнарга һәм табигый паркларга баруын чикләү;
– торак пунктлар, бакчачылык ширкәтләре, балалар ял итү һәм сәламәтләндерү объектлары чикләре буйлап, автомобиль юллары һәм тимер юллар бүлеп бирелгән полосалар чикләрендә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр буйлап янгынга каршы төзекләндерү үткәрү (киңлеге 15 метрдан да ким булмаган минеральләштерелгән полосалар булдыру) ;
– урман фондларындагы янгыннарны сүндерүгә халыкны җәлеп итү өчен шартлар тудыру;
– дача һәм бакчачылык җәмгыятьләре территорияләрен, автомобиль юлларына һәм тимер юлларга ягулык калдыкларыннан, коры үләннәрдән, камышлардан, киселгән ботаклардан һәм агачлардан бүлеп бирелгән полосаларны чистарту;
– каты көнкүреш калдыкларының полигоннарына һәм янган чүп-чарның чүплекләренә су сибү;
– пиротехник әйберләрне сату һәм куллану буенча чикләүләр кертү;
– булган янгыннарны бетерү өчен финанс чаралары, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү чаралары һәм башка матди ресурслар резервларын булдыру;
– кирәк вакытта куллану өчен су ташу һәм җир казу техникасын әзерләүне оештыру;
– янгынга каршы махсус режим шартларында янгын куркынычсызлыгы чараларының үтәлеше турында халыкка мәгълүмат бирүне оештыру;
– Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка чаралар.

4. Янгынга каршы махсус режим вакытлыча чара булып тора һәм гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген, мөлкәтен, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрен янгыннан саклау, озакка сузылган яки күпләп янгыннар чыгуга китерә торган коры, эссе, җилле яки салкын һава торышы вакытында объектларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, табигать афәтләре һәм зур аварияләр нәтиҗәләрен бетерү максатларында гына урнаштырыла.

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча норматив хокукый актлары нигезендә, шулай ук үз инициативасы буенча (нигезләре булганда, әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган) бирелгән вәкаләтләр чикләрендә Зеленодольск муниципаль районы

территориясендә яки территориясенең бер өлешендә махсус янгынга каршы режимны билгели һәм гамәлдән чыгара.

Муниципаль район территориясендә яисә территориясенең бер өлешендә махсус янгынга каршы режим билгеләнгән очракта, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты бу хакта Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисенә - Татарстан Республикасы Премьер-министрына һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә хәбәр итә.

6. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының янгынга каршы махсус режим билгеләү турындагы норматив хокукый актында түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

- янгынга каршы махсус режим урнаштыру өчен нигез булып торган хәлләр;
- янгынга каршы махсус режим урнаштыру кирәклеген нигезләү;
- янгын куркынычсызлыгының өстәмә таләпләре исемлеге;
- янгынга каршы махсус режим билгеләнә торган территорияләр;
- махсус янгынга каршы режим гамәле башлану вакыты һәм датасы яисә махсус янгынга каршы режим гамәлдә булу вакыты;
- махсус янгынга каршы режим шартларында янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән җирле үзидарә органнарына, оешмаларга (милек рәвешләренә бәйсез рәвештә) һәм гражданнарга йөкләмәләр (тәкъдимнәр) исемлеге.

7. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының янгынга каршы махсус режимны билгеләү (гамәлдән чыгару) турындагы норматив хокукый акты янгынга каршы махсус режим билгеләнгән территориядә халыкка түләүсез нигездә массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм (яки) рәсми рәвештә игълан итү юлы белән җиткерелә.

8. Махсус янгынга каршы режим урнаштырылган очракта, оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына карамастан, барлык юридик затларның гамәлләрен координацияләүне Зеленодольск муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе гамәлгә ашыра.

9. Физик һәм юридик затлар, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, тиешле территориядә билгеләнгән махсус янгынга каршы режим шартларында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәргә тиеш.